ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2024 елда җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинның 2024 елда җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына:

2.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен, гражданнар җыеннарында, җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау кампанияләре барышында республика халкыннан кергән наказларны һәм тәкъдимнәрне карау эшен системалы нигездә дәвам итәргә.

2.2. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе сенаторлары белән берлектә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисенә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатьләрен үткәрү эшен дәвам итәргә.

2.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары утырышларында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышларында контроль мәсьәләләрне карау тәҗрибәсен дәвам итәргә.

2.4. Россия Федерациясе тышкы сәясәтенең яңартылган концепциясен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы нигезендә парламентара хезмәттәшлек линиясе буенча, шул исәптән чит илләрдә яшәүче ватандашлар белән хезмәттәшлек буенча, регионара һәм халыкара багланышларны алга таба үстерүгә ярдәм итәргә.

2.5. Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең, Идел буе федераль округы Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарының профильле комитетлары белән уртак күчмә утырышлар үткәрү тәҗрибәсен дәвам итәргә.

2.6. Булачак Татарстан Республикасы Рәисен сайлауларны һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларны (2025 елның сентябре) әзерләүдә һәм хокукый тәэмин итүдә актив катнашырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына:

3.1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

3.2. 2025 елда Казан шәһәрендә үткәрелә торган халыкара һәм федераль дәрәҗәдәге чараларда (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 30 еллыгы, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы, «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы һәм башкалар) актив катнашырга.

3.3. Депутатларга беркетелгән сайлау округларында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы, Ватанны саклаучылар елы кысаларында Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында үткәрелә торган чараларда актив катнашырга.

3.4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетлары тарафыннан үткәрелә торган «түгәрәк өстәлләрдә» һәм парламент тыңлауларында катнашу тәҗрибәсен дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 177-VII ДС